СОВЕТ
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

с.Степная Шентала

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.02.2025 № 83

**Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Нигезләмәне раслау турында Советның 2014 елның 19 ноябрендәге 84 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Указына туры китереп Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 84 номерлы карарына 3 нче кушымтаның 6 бүлегендәге 6.2 пунктының 13 нче искәрмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<13> Хисап чорында счетларга кергән акчаларның суммалары, әгәр мондый акчаларның гомуми суммасы затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында һәм аннан алдагы ике елдагы гомуми кеременнән артыграк булса, күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен суммалар хисап датасына Россия Банкы курсы буенча сумнарда күрсәтелә.".

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзартымда калдырам.

**Кыр Шонталы авыл җирлеге Башлыгы** **Г.Н. Кыямова**